СОВЕТ
НОВОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 3, с.Новый Кырлай,
Арский муниципальный район, 422035

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

**Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

« 02 » июль 2020 ел № 102

## Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат биргән өчен, әгәр әлеге белешмәләрнең дөрес түгеллеге артык әһәмиятле булмаса, җаваплылык чаралары турында карар кабул итү Тәртибе хакында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында» федераль закон, «Контракт буенча муниципаль вазыйфа, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучыгражданнаряисәконтракт буенчамуниципаль вазыйфа, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү тәртибе хакында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы, «Контракт буенча муниципаль вазыйфа, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы граждаңнар яисә контракт буенча муниципаль вазыйфа, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрнеңдөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында» 2017 елның 19 июлендәге 57-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары, Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Уставы нигезендә Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти

характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат биргән өчен, әгәр әлеге белешмәләрнең дөрес түгеллеге артык әһәмиятле булмаса, җаваплылык чаралары турында карар кабул итү Тәртибен расларга (кушымта).

2. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров

СОВЕТ НОВОКЫРЛАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Арча муниципаль
районы Яңа Кырлай
авыл җирлегенең 02
июль 2020 ел, №102
карарына кушымта

Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат биргән өчен, әгәр әлеге белешмәләрнең дөрес түгеллеге артык әһәмиятле булмаса, җаваплылык чаралары турында карар кабул итү Тәртибе

1. Әлеге Тәртип Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат биргән өчен, әгәр әлеге белешмәләрнең дөрес түгеллеге артык әһәмиятле булмаса, җаваплылык чаралары (алга таба-җаваплылык чаралары) турында карар кабул итү процедурасын регламентлый.

2. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы $7^{3-1}$ өлеше нигезендә керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес яки тулы булмаган белешмәләр биргән муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга түбәндәге җаваплылык чаралары кулланыла:

1) кисәтү;

2) депутатны, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасынАрча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Советында, җирле үзидарә сайлау органында вазыйфа биләүдән мәхрүм итепАрча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге җирле үзидарә сайланулы органында аның вәкаләтләре срогы беткәнче вазыйфасыннан азат итү;

3) даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан азат итү, аның вәкаләтләре вакыты беткәнчегә кадәр даими нигездә вәкаләтләрен гамәлгә ашыру хокукыннан мәхрүм итү;

4) Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Советында үз вәкаләтләре срогы тәмамланганчы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында вазыйфаларны биләүне тыю;

5) вәкаләтләр срогы тәмамланганчы даими нигездә вәкаләтләрен үтәүне тыю.

3. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга карата әлеге Тәртипнең 2 пунктында санап үтелгән җаваплылык чараларының берсен куллану турындагы

мәсьәлә Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы тарафыннан карала.

Күрсәтелгән мәсьәләне карау өченнигез булып«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы $7^3$ өлешендә каралган муниципаль вазыйфаны биләп торучы затка җаваплылык чараларын куллану турында Татарстан Республикасы Президентының Советка кергән гаризасы тора.

4. Җаваплылык чараларын куллану турында Татарстан Республикасы Президенты гаризасы кергән көннән өч айдан да соңга калмыйча Совет тарафыннан карала.

5.Совет муниципаль вазыйфаны биләүче затка аңа карата күрсәтелгән мәсьәләне карау датасына кадәр биш эш көненнән дә ким булмаган вакыт эчендә җаваплылык чараларын куллану турындагы мәсьәләне карау хакындаязма рәвештәхәбәр итә.

Совет утырышы урыны һәм вакыты турында хәбәр ителгән муниципаль вазыйфаны биләп торучы затның килмәве Татарстан Республикасы Президентының җаваплылык чараларын куллану турындагы гаризасын карауга комачауламый.

6. Муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата җаваплылык чараларын куллану турында Татарстан Республикасы Президенты гаризасы Совет Регламентында билгеләнгән тәртиптә Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы утырышында карала.

Күрсәтелгән мәсьәләне караганда, муниципаль вазыйфаны биләп торучы затка тапшырылган мәгълүматлар буенча аңлатмалар бирү мөмкинлеге бирелергә тиеш.

Муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата җаваплылык чараларының берсенкуллану турындагы мәсьәләне караганда, депутатлар тарафыннан мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу буенча таләпләр үтәлергә тиеш. Совет утырышында рәислек итүче депутатларга мәнфәгатьләр каршылыгының барлыкка килү мөмкинлеге турында хәбәр итәргә тиеш.

Мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яки җайга салу максатыннан, мәнфәгатьләр каршылыгының бер ягы булган депутатрәислек итүче тарафыннан карар кабул итүдән читләштерелә.

7. Татарстан Республикасы Президенты гаризасын карау нәтиҗәләре буенча муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата җаваплылык чараларын куллану яисә җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турында карар кабул ителә.

Әлеге карар Регламентта билгеләнгән тәртиптә кабул ителә.

Татарстан Республикасы Президенты гаризасы кергән депутат тавыш бирүдә катнашмый.

8. Җаваплылык чарасын куллану турындагы карар гаделлек, чамалылык, пропорциональлек һәм котылгысызлык принципларына нигезләнә, кылынган коррупциячел хокук бозу характерын, аның зурлыгын, шулай ук муниципаль вазыйфа биләгән зат тарафыннанүз вазыйфаи бурычларын (вәкаләтләрен) үтәгәндә башкарылган эшләренең нәтиҗәләрен исәпкә алып, коррупциягә каршы

тору максатларында билгеләнгән башка чикләүләрне, тыюларны һәм бурычларны үтәү нигезендә кабул ителә.

Хисап чорында керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр биргән өчен бары тик бер генә җаваплылык чарасы кулланылырга мөмкин.

9. Җаваплылык чарасын куллану турындагы карарда коррупциячел хокук бозуга күрсәтмә, бозылган норматив хокукый актлар нигезләмәләре, муниципаль вазыйфаны биләүче зат тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә карарга шикаять бирү хокукы булырга тиеш.

10. Җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турындагы карарда мондый баш тартуның дәлилләнгән нигезе булырга тиеш.

11. Җаваплылык чарасын куллану яисә җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турындагы карарның күчермәләре кабул ителгәннән соң биш эш көне эчендә муниципаль вазыйфа биләүче затка имза куйдырып тапшырыла яисә тапшыру турында хәбәрнамә белән почта аша җибәрелә, шулай ук Татарстан Республикасы Президентына җибәрелә.

Җаваплылык чарасын куллану турында карарны муниципаль вазыйфаны биләп торучы затка тапшырып булмаса яки әлеге зат карарны кул куеп алудан баш тартса, Совет рәисе урынбасары югарыда күрсәтелгән затка җаваплылык чарасын куллану турындагы карар хакында хәбәр итеп булмау яисә танышудан баш тартуы турында акт төзи.

12. Җаваплылык чарасын куллану яисә җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турындагы карарга Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.